**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 3-38 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының 2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы «Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы “Татарстан Республикасындагы җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы «Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарына (Казан шәһәре Думасының 2010 елның 27 мартындагы 19-1 номерлы, 07.06.2012 елның
21-14 номерлы, 2012 елның 24 октябрендәге 9-17 номерлы, 2013 елның 14 мартындагы 14-21 номерлы, 2013 елның 16 октябрендәге 16-25 номерлы, 2014 елның 28 августындагы 5-35 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 29-36 номерлы, 2017 елның 17 августындагы 11-19 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 13-25 номерлы, 2019 елның 20 июнендәге 15-34 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 20-1 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге 3-17 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 22-19 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 5-30 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 7-31

номерлы, 2024 елның 18 декабрендәге 6-35 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 номерлы кушымтаны әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләргә;

1.2. 4 номерлы кушымтаны әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләргә;

2. Әлеге карарның йогынтысы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**